«Кайсы җирдә Муса булса, шунда фиргавен бар», яки вәисевчеләрне эзәрлекләү тарихыннан

Елдан-ел вәисиләр хәрәкәтенең феномены тарихчыларны һәм киң җәмәгатьчелекне үзенә җәлеп итә. Китап һәм журнал басмаларында вәисиләр хәрәкәтенә төрледән-төрле карашлар бар. Шул карашлар арасында: «сугышчан фундаментализм»[1], «вahhабчылык»[2] күренешләрен атарга була. Күпчелек, «сәяси ислам» термины артына качып, ислам динен хәлиткеч фактор итеп карамау ягында тора. А. И. Ионова[3] кебек фикер йөрткәндә, милли-азатлык хәрәкәте һәм милли горурлык (аныңча милләтчелек. — *К. Ш.*) нигезендә ислам дине тора. Менә шулай итеп ул «милләтчелек идеологиясенең үсү» чыганагын ислам дине дип саный.

Фиркаләр туу, җәмгыятьтәге канәгатьсезлек, төрле баш күтәрүләр башлану беренче булып икътисади сәясәткә бәйләнгән. Әлбәттә, боларның барысына инкыйлаби хәл чорында да, аннан соң да, ислам һәм башка диннәрнең сәясәткә, икътисади хәлгә йогынтысы төрлечә була. Дин белән сәясәтнең аермалыкларын аңлаганда гына без дөрес фикергә килә алабыздыр.

Октябрь инкыйлабы чорында, исламга таянып, тагын да югары үрләргә менә алган вәисиләр хәрәкәте моңа ачык мисал булып тора. Тарихи чыганаклар бу фикеребезне турыдантуры исбат итәләр. 1906 елгы «Вакыт» газетасының 22 нче санында «Тагын бер мөселман фиркасе» дигән мәкаләдә вәисиләр хәрәкәте турында языла. Басманың авторы вәисиләрнең бер тарафдары белән әңгәмә кора һәм соңыннан шундый фикергә килә: «Бу кешенең үз сүзеннән мәзһәбләре хакында һич шәй (нәрсә. — *К. Ш.*) аңламадым исә дә, дин илә сәясәтне аера алмадыклары сәбәбеннән, беренче икенчесенә катышдырып вә бу җәһәтдән үзләрене аерым мәзһәб санап йөрмәктә улдыклары кабул итәргә мәҗбүр булдым», — ди.

Милли-азатлык хәрәкәтенең төп бурычы булып мөстәкыйль һәм суверен дәүләт төзү мәсьәләсе тора. Казан ханлыгы алынганнан соң, бу

бурычны Габдулла Галиев, Батырша, абыз бабайлар үз алларына куйганнар. XIX гасырның икенче яртысында татар халкының үз идарәсен, үз дәүләтен төзү мәсьәләсен күтәргән кеше, татар халкының профессиональ язучысы Бәһаветдин Вәисев була. Бәһаветдин: «Без, болгарлар, үз дәүләтебез, үз тәртипләребезне оештырып, бернинди урындагы властьларга буйсынмыйча яшәргә телибез», — ди. «Бары тик патшаның үзенә генә буйсынабыз, калган эшләрдә үзебезчә яшибез», — ди. Бу киң федерация таләп итү, татар җирендә чит идарәчелекне кире кагу булды, милли-азатлык таләбен тормышка ашыру өчен көрәш булды[4]. Вәисевчеләрнең тәгълиматлары күпкырлы. Шуңа күрә, алда әйтелгәнчә, бу хәрәкәт галимнәр арасында билгеле бер дәрәҗәдә фикер буталчыклыгы тудыра. Бәһаветдин Вәисевнең дөньяга карашлары идеалистик һәм утопистик социализм, анархизм, стихияле материализм характерында булган. Кыскасы, вәисевчеләр хәрәкәтен тулаем алганда, милли-азатлык хәрәкәтенең антифеодал-сыйнфый һәм антиколониаль характердагы дин пәрдәсе астында алып барылган үзенчәлекле бер тармагы, дип әйтергә була. Дин байрагы астындагы сәяси протест — бер татар халкында гына түгел, ә тарихи процессның билгеле бер этабында кайбер башка халыкларда да күзәтелә торган ижтимагый күренеш.

Төрле формада һәм юнәлештә яшәп килгән вәисиләр хәрәкәте XX гасырга да килеп керергә өлгерә. Бу хәрәкәт 1862 нче елда башланып 1920 нче елларга кадәр үзенең үсешен дәвам итә. Егерменче елларга инде ул тулаем сәяси партия дәрәҗәсенә үсеп, үзенең программасын булдырып, җыелышларын да үткәрә. Хәрәкәтнең соңгы җитәкчесе Газизҗан Вәисев 1940 елда да эзәрлекләүгә дучар була[5].

«Бу хәрәкәтне ничек кенә атасаң да, ул дөреслек, гаделлек, рухи чисталык өчен көрәш. Алар йөз ел дәверендә диктаторлар белән көрәштеләр. “Сектант”лар хәрәкәте кебек башланып киткән бу хәрәкәт акрын гына зур сәяси көрәшкә әверелде. Гайнан Вәисев беренчеләрдән булып Ислам социализмы концепциясен төзеде. Икътисад, сәясәт, мәдәният өлкәсендә дә большевиклар программасын тулысы белән диярлек, үз программаларына керттеләр. Большевиклар бөтен мәсьәләләрне сыйныфлар көрәшенә таянып хәл итсәләр, вәисевчеләр бер Аллага — Исламга таяндылар»[6].

Укучыга тәкъдим ителә торган мәгълүмат Гайнан Вәисевнең улы Мидхәт Вәисев архивыннан табылды. Бу — Газизҗан Вәисев тарафыннан үлеме алдыннан дүрт ай элек язып калдырылган сәяхәтнамә. Язманың ахырында әйтелгәнчә, ул хатирәләрнең икенче кисәген дә язарга уйлый, ләкин бу эшне аңа эшләргә насыйп булмый. Без аны сезгә, гарәп графикасыннан кирилл графикасына күчереп, һәм берникадәр кыскартып беренче тапкыр тәкъдим итәбез.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Левин З. И. Реформа в исламе. Быть или не быть?: опыт системного и социокультурного исследования. – М., 2005. – С. 194.
2. Хабутдинов А. Ю. Ваххабизм в Татарстане: сегодняшняя ситуация в исторической ретроспективе // Вестник Евразии. – 2000. – № 2 (9). – С. 86-107.
3. Ионова А. И. Ислам в шкале национальных ценностей // «Воинствующий ислам»: Сб. ст. – Москва, 1988. – С. 168.
4. Алишев С. Х. Казан ханлыгы тарихыннан. – Казан, 2003. – Б. 152.
5. Книга памяти. Татарстан [Электронный ресурс]. — Режим доступа: http://www.memo.ru/memory/kazan/kaza11.htm.
6. Вәлиев Р. К. Өзелгән дога // Мирас. – 2003. – № 1. – Б. 20.

Камил Шәкүрев,
КДУ аспиранты

Газизҗан Бәһаветдин улы Вәисзадә әл-Болгари тарафыннан язылган кыскача тарихи белешмә һәм сәяхәтнамә

Август 1963 ел.

Үзбәкстанда Янги-Юл шәһәрендә яшәүче Әдибә Газизҗан кызы Вәисзадә әл-Болгарида сакланучы оригиналдан мин, Әхмәд Мидхәт Сардар Гайнан улы Вәисзадә әл-Болгари, 17-19 декабрь 1982 елны күчердем.

Тарихи ядкәр вә сәяхәт хатирәләре һәм бабаларыбыз әһле болгарлар турында азрак мәгълүмат.

Бу хөрмәтле вә һиммәтле* кардәшләребез Камилә бинте Нургали әл-Болгари, сезгә, иптәшегез Фазыйлга, улыгыз Шамилгә вә барча угыл-кызларга, ага-әхи** вә апа һәм сеңел кардәшләргә, без дәрдмәндләрне*** искә төшереп, сораучы яхшыларга аманлык****, сәламәтлек белән, бәхет-сәгадәт белән, озын вә тыныч яшәүләрегезне теләп, дәрдмәнд бабагыздан, апагыздан, кызыбыз Әдибәдән вә бөтен гаиләбездән күптән-күп сәлам.

Без дәрдмәндләрне исегезгә төшереп җибәргән һәдия-бүләкләрегез исән-бөтен килеп кулыбызга иреште. Күп еллардан бирле каз-кош итләрен тәнавел***** кылмаган идек, шайәт дәртләребезгә шифа вә дәва булсын икән дип, дөньяда терек булганнар исән-аман, тыныч вә озын яшәсәләр икән дип, хәер-догалар кылдык. Дөньядан үткәннәрнең җаннары җәннәттә булса икән дип, фатиха кылдык, рәхмәтләр булсын икән.

Хуш, инде кадимгә тарихтан азрак язабыз, шәт исегездәдер, ата-бабаларыбыз үзләрен Болгари дип йөриләр иде: язган хатларында һәм башка язуларга имза кылып кул куйганда әл-Болгари дип язалар иде. Ни өчен әл-Болгари дип йөргәннәр икән?

Урта гасырда, димәк моннан элгәре күп еллар чамасы, Ак Идел һәм Кама дәрьялары****** зур, озын Идел дәрьяга кушылган җирдә, димәк Идел буенда кадимге болгарлар зур бер хөкүмәт булып яшәгәннәр. Хөкүмәт мәркәзе-пайтәхетләре******* Болгар дип мәшһүр булган.

Болгар халыклары унике төрле милләт яхуд унике төрле халыктан оешкан зур хөкүмәт булган. Бу унике төрле халыкларның иң зурысы, безнең бабаларыбыз болгарлар төркичә сөйләгәннәр. Икенчесе, зур вә күп халык — башкортлар. Башкортлар һәм төркичә сөйләгәннәр. Димәк, төп болгарлар безнең бабаларның вә башкортларның теле төрки тел булган. Унике төрле халыкларның өченчесе чуашлар, телләре чуашча. Дүртенче мордва-мукшылар. Мордваларның телләре мукшыча. Бишенчесе — чирмешләр, телләре чирмешчә. Алтынчысы — арлар, телләре башка. Жиденчесе вәтәкләр, телләре аерым. Янә биш төрле милләт.

Менә бу унике төрле милләт оешып зур хөкүмәт булып тыныч вә тату яшәгәннәр. Милләтләре, телләре, диннәре, гореф-гадәтләре һәр төрле булган. Безнең бабаларыбыз төп болгарлар вә башкортлар гарәпләрдән, гарәп галимнәреннән вә илчеләреннән ислам динен өйрәнеп, мөселман булганнар. Ул заманнарда иң мәдәниятле, гыйлем-һөнәрдә бөтен дөньяда иң шөһрәтле, шәрык вә гареп халыклары эчендә мәдехле********, иң яхшы вә тугры халыклар безнең бабаларыбыз болгарлар булган. Шәһри Болгарда зур мәдрәсәләр, мәсҗедләр, бәләнд********* сарайлар, манаралар, зәркәнханәләр вә һәртөрле кярханә-мастерскойлар булган. Һәр җәйне җәй көннәрендә зур ярминкә булган. Ярминкәдә шәрыктан********** гарәпләр, иранлылар, һиндлар, кытайлар, гарептән********** славяннар, руслар, немецлар вә башкалар, һәр төрле маллар белән шәһри Болгарда алыш-биреш, сату-сәүдә кылганнар икән.

Сәүдәгәрләрнең ерак җирләрдән алып килгән маллары сатылып бетмәсә кире алып китмәгәннәр, шәһри Болгарда ярминкә булган урында калдырып китерәләр икән. Икенче хәлгә кадәр шул урында тора икән. Чөнки болгар халыкларында угрылык һәм алдау, ялганчылык вә хәйлә-хыянәтләр булмаган икән.

Менә шулай яхшы вә тыныч яшәгән бер заманда шәрыктан Аксак Тимер дип мәшһүр канхур********** залимнең гаскәрләре шәһри Болгарга һөҗүм кылып, мәсҗед-мәдрәсәләрне, зур вә бөек сарайларны, бөтен шәһәрне вәйран********** кылганнар. Шәһәрдәге тыныч халыкларны кырганнар, фәкать авылларда һәм урман-болыннарда гына болгар халыклары исән калганнар...

---

* Һиммәтле — киң күңелле.
** Әхи — ир кардәш.
*** Дәрдмәнд — кайгысы булган кеше, бичара.
**** Аманлык — иминлек.
***** Тәнавел — авыз итү.
****** Дәрья — елга.
******* Пайтәхет — башкала.
******** Мәдехле — мактаулы.
********* Бәләнд — бөек.
********** Шәрык — көнчыгыш.
********** Гареп — көнбатыш.
********** Канхур — канэчкеч.
********** Вәйран — җимерү.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткәннәр: «заман мөтәгайяр*, әшхас** мохталиф»***. Ягъни заман үзгәрә һәм халыклар да төрлечә була, дигәннәр.

Менә шундый караңгы вә авыр бер заманда болгар бабаларыбызның асыл нәселләре безнең атабыз Бәһаветдин Әмир Хәмзә улы Әмир Хәмзә Вәис улы, Вәис Тамматы улы, Тамматы Һашими әл-Болгари мәйданга чыккан. Татар байлары, морзалары вә мөнафикъ татар муллаларына һәм залим падишаларга, аның сакчыларына, губернаторлар, помещиклар, алпавытлар вә жандармнарга каршы зур җиһад****, хокук, ирек, азатлык өчен көрәшен башлаган.

Михнәткәшләрне*****, юлдан адашкан бичараларны, болгар халыкларын тугры юлга, хак юлга чакырган. Азатлык азанын ишеткән фәкыйрьләр, бичаралар, михнәткәшләр, авыллардан килеп дәрдмәнд атабызның башлап бара торган тугры юлына кушыла башлаганнар. Дәрдмәнд атабыз әйткән, безгә падиша кирәкми, шуның өчен без, болгар мөселманнары, падишаны саклар өчен солдат бирмибез, дип. Без болгар мөселманнары, падиша түрәләре, чиновникларга бүрек салмыйбыз, дип, һәм налог бирмибез, чөнки без, болгар халыклары үзебезнең ата-бабаларыбызның җирендә торабыз, дип. Без, болгар мөселманнары, указной муллаларга кушылып йөрмибез, чөнки указны мөфти бирә, мөфти керәшен, мөфтиләрнең башлыклары христиан миссионерлары, ислам дошманнары. Шуның өчен указной муллаларга ойу дөрес имәс, дигәннәр. Имам булыр өчен гыйлем белән гамәл кыла торган тәкъва галимне мөселманнар үзләре тәгаен кылырга тиеш, дигәннәр.

Җир-су, урманнар гомум халык милке, дигәннәр икән.

Зирагатьче****** михнәтчеләр******* үз гаилә-җәмәгатьләре белән никадәр игәргә көч-куәтләре җитә, шулкадәр җир үз милекләредер.

Урманнар һәм шулай, ягъни гаиләгә никадәр утын вә агач кирәк булса, урманнан утын вә агачлардан файдалану дөрес, дигәннәр.

Дәрдмәнд атабызның тәшвикатьләре********, фикер вә хәрәкәтләре фәкыйрь бичаралар эчендә таралып, зураеп китүдән курыккан байлар, муллалар, түрәләр, алпавытлар, жандармнар, залим падишалар тизрәк атабызны халыктан яшерергә һәм төрле яла-ялганнар, хәйлә-хыянәтләр белән яманлап бичара фәкыйрь халыкны байлар, монафикъ муллалар алдаганнар.

Дәрдмәнд атабыз Бәһаветдин Әмир Хәмзә улы болгар мөселманнары, фәкыйрь михнәткәшләрнең вәкилләре белән сәяси вә икътисади, вә зирагать, вә җир-су һәм урманнар турында киңәш, мәслихәт мәҗлесләре вакытында залим канхур жандармнар, хәрәмхур********* байлар, монафикъ муллалар, бөтен залимнәр, хаиннар********** берләшеп, дәрдмәнд атабызын өйләренә һөҗүм кылганнар.

Дәрдмәнд атабыз һәм мәҗлестә хазир булган вәкилләр зур гайрәт вә фидакарьлек белән залимнәргә каршы торганнар. Саук********** кышта бер һәфтә********** мөдафәга********** кылганнар. Сынган тәрәзәләрдән өйгә саук кергәч, өшегән, туңган һәм ачлыктан гажиз булган, хәлдән тайган мөҗаһидләрне залимнәр камап әсир кылганнар. Өйдәге кадимге тарихи, кадерле, кыйммәтле китапларны вә бөтен әсбап-шәйләрне талап туздырганнар.

Дәрдмәнд атабызны һәм вәкилләрне, аяк-кулларын бәйләп, крипескә-төрмәгә япканнар. Миһербан анабызны балалары белән гыйнвар саукларында, кар-буранда өйдән күчәгә-урамга, сөреп-һәйдәп чыгарганнар. Бу вакыйга 1886 нчы елда гыйнвар башларында булган (Бу сан дөрес түгел. Бәһаветдин Вәисевнең йортын камау 1884 елда була. — *К. Ш.*).

Шул вакытта мин, Газизҗан өч айлык бала-нарасый булганмын. Икенче бала Гаян

* Мөтәгайяр — төрле, үзгәргән.
** Әшхас — кешеләр.
*** Мохталиф — төрле.
**** Җиһад — дин өчен көрәш.
***** Михнәткәш — хезмәт иясе, авырлык чигүче.
****** Зирагатьче — игенче.
******* Михнәтче — хезмәт иясе.
******** Тәшвикъ — өндәү.
********* Хәрәмхур — әрәмтамак.
********** Хаин — сатлык.
*********** Саук — суык.
************ Һәфтә — атна.
************* Мөдафәга — саклану.

Бәһаветдин улы биш яшь, өченче бала Гайнан тугыз яшь, дүртенче бала Галәветдин Бәһаветдин улы ун яшьтә икән.

Миһербан анабыз балаларым саукда өшеп, туңып калмасыннар дип, күчәдә* дивар-койма ышыгында бер бәрчәктә безне юрган ябып, астына палас ябып канат астына җыеп, тилмереп, Хакка ялварып утырган икән. Күчәдән узган байлар вә аларның малайлары мәсхәрә кылып, килеп төкереп, таш атып: «менә шулай кирәк падишага, байларга, муллаларга итагатъ кылмаганнарга, шулай кирәк», — дип узганнар.

Әмма фәкыйрьләр, михнәткәшләр узганда, «әй, бигөнаһ нарасыйлар, сабый балалар бу саук буранда ачлыкта, саукка ничек чыдап тәкатъ кылып утыралар икән?» — дип, жәлләп узганнар. Әмма начар вә иске булса да, җылы өйгә-квартирга алып җылытырга байлар, түрәләр һәм муллалардан курыкканнар.

Залимнәр, канхурлар, талаучылар, каракларның бу вәхшәтләре бөтен Казан каласына фаш булган.

Шул фажигаләрне ишеткәч, руслардан карт юрист, адвокат, демократ Иван Давыдов исемле 80 яшендә карт: «мин байлардан, муллалардан һәм поплардан, түрәләрдән, жандармнардан курыкмыйм, бигөнаһлар, сабыйларга ярдәм кирәк», — дип, ике чана («барабыз»)**, ике арзан извозчикны алып килеп, безне, өшегән, туңган балаларны, барыбызны да үзенең квартирына алып килеп, курасындагы аерым бер өйне җылытып безгә биргән һәм азрак җылы киемнәр биреп ярдәм кыйлган икән.

Әле дә исемдә, Давыдовлар Казан каласында Академический слободада үз өйләре, зур куралары һәм баг-бакчалары, зур голландский сыерлары һәм бик күп тавыклары бар иде. Үзләре өч җан, карт-карчык һәм кухаркалары бар иде. Чиркәүгә бармыйлар, попларны китермиләр, аракы эчмиләр һәм чучка-дуңгыз гушын*** һәм маен ашамыйлар иде.

Давыдовларда без ике кыш, ике җәй икамәт**** кыйлдык. Миһербан әнкәебез белән һәр көн крипескә, дәрдмәнд атабызга фәкыйрьләрчә азык алып бара идек, чөнки дәрдмәнд атабыз анда төрмәдәге азыкларын ашамаган, өйдән килгәнгә канәгать һәм рийазат***** кылган икән. Дәрдмәнд атабызны безгә, балаларга һәм миһербан анабызга күрсәтмиләр. Мин дөнья күзе белән мөбарәк атабызның мөбарәк йөзләрен күрә алмадым. Төрмәнең тәрәзәләренә якынрак барып: «Әткәй, без килдек!» — дип кычкыра идем. Сакчы жандармнар — залимнәр безне куркытып куалар иде. Без алып барган һәм дәрдмәнд атабызның керле-канлы күлмәкләрен, тастымалларын, залим жандармнар чыгарып безгә ташлыйлар иде. Мин йөгереп барып ала идем.

Крипес курасыннан чыгып ераграк бер сайә вә тыныч җиргә барып, дәрдмәнд атабыздан чыккан табакларны һәм күлмәкләрне күреп, елап, без күзләребезгә үбеп сөртә идек. Табак-савытларда күгәргән һәм каткан сохарилар була иде. Шул сохариларны бер-бер тикшереп, сындырып карый идек. Сохариларда дөге ярмасы кеби вак-вак кәгазьләр чыга иде. Бу язуларны миһербан әнкәебез укып безгә дәрдмәнд атабызның сәламнәрен һәм вәгазьләрен — нәсихәтләрен һәм исбатларын, зар-зар елап төшендерә иде.

Дәрдмәнд атабызның нәсихәт һәм васыятьләре: залимнәрдән курыкмагыз, батыр булыгыз, гайрәтле булыгыз. Һәрбер авырлык, кыенлыкларга сабыр кыйлып чыдагыз. Шаять якын заманда зур инкыйлаб булыр. Залим падиша бөтен җәмәгатьләре белән бер көндә һәлак булырлар. Аның сакчылары, жандармнар, канхурлар, министрлар, губернаторлар, алпавытлар, байлар, монафикъ муллалар калмаслар. Маллары, бичара фәкыйрьләрне талап, михнәткәшләрнең көчләреннән файдаланып, алдап, урлап, хәйлә-хыянәтләр белән җыйган маллары, алтыннары, залимнәрнең башларына бәла булыр, дип яза иде.

Арып-талып фатирыбызга кайта идек. Менә шулай Давыдовларда өч елга якын икамәт кыйлдык. Давыдовлар, карт-карчык, икесе дә бер айда вафат булдылар. Жандармнар, полициячеләр килеп, Давыдовларның өйләрен, бөтен нәрсәләрен язып, өйләрен пичәтләделәр. Безне ханәдән****** урамга куып чыгардылар.

---

* Күчә — урам.
** «Барабыз» — XIX гасырда бу сүз белән извозчикларны атаганнар.
*** Гуш(т) — ит.
**** Икамәт — бер урында тору, яшәү.
***** Рийазат — ризалык.
****** Ханә — өй.

Миһербан анабыз зар-зар елап: «Әй балаларым, бәгырьләрем, инде кайда барабыз? Бу бивафа дөньяда азатлык, тынычлык кайчан булыр икән?» — дип, миһербан анабыз һәм без, яшь балалар, зар-зар дау кылып елаша идек.

Академический слобадада буш фатирлар булса да, жандармнардан, полицияләрдән куркып безгә фатир бирмиләр иде. Дәрдмәнд атабыз иртәгә яки тиз көннәрдә азат булыр дип, авылга бабаларга бармый тора идек. Казан каласына якын тау башында Ослан дигән поселокка барып азрак тордык. Анда фатир хакы бик кыйммәт һәм калага, крипескә дәрдмәнд атабызның хәлләрен белер өчен бару-килү ерак иде.

Ниһаять, авыр вә кыенлыкта калгач авылга кайттык.

Сембер губернасында, Бидәнге дигән авылда миһербан анабызны, алты айлык нарасый ятим баланы үзләренә бала кылып баккан, тәрбия кылган һәм укыткан хәзрәт баба Габделлатыйф вә аның карчыгы хөрмәтле ананың балалары булса да, үсмәгәннәр. Шуның өчен үзләренә бала вә варис кылып, безнең әнкәбезне алты айлык вакыттан тәрбия кылганнар. Хәзрәт баба зур галим һәм тәкъва булган. «Мөхтәсарел-викая»не гарәп теленнән безнең төрки теленә иң беренче булып тәрҗемә кылучы галим шул хәзрәт баба булган. Шул тирәдә генә имәс, бәлки Казан, Уфа, Оренбург вә башка калаларга мәгълүм вә атаклы галим булган. Халыкларның теләге белән шул авылга указный имам булган. Ләкин «без указга, законга итагать кылмыйбыз, дөрес түгел», — дип указны кире кайтарып Собраниега җибәргән. Болгар мөселманнары, михнәткәшләрнең вәкилләренең мәслихәт җыелышларына жандармнар, полицияләр, байлар, залимнәр һөҗүм кылып, камап төрмәләргә, зинданга япканда, хәзрәт бабаны һәм камап зинданга япканнар икән.

Ничә айлардан киин* авыру һәм картлык сәбәпле төрмәдән чыгарганнар. Без яңа авылга кайткан гына идек, хәзрәт баба һәм өйгә кайтып килде. Авыру иде. Берничә көннән киин вафат булды. Хак Тәгаләнең рәхмәтедер. Җайлары, барча мөэмин — мөэминәләрнең рухлары җәннәттә булса икән.

Авылга кайткач, без ач һәм ялангач булмадык. Хәзрәт баба үзе исән вакытта васыятьнамә язып, йорт-җирләрне, ат, сыер, сарыклар вә бөтен мал-милекләрне миһербан анабыз, һәм без балаларга дип, язып, тәсдыйк кылдырганнар икән. Безнең әнкәбезне яшь вакытларында хәзрәт баба үзе белгән гыйлемнәрне гарәп, фарсы телләрендәге гыйлемнәрне укытып, һәммәсен яхшы өйрәткән икән. Әнкәбез һәм зур галимә иде. Яшь бала вакытыбызда без барыбыз иң әүвәл әнкәбездән гыйлем, белем алдык. Без авылга кайткач, авылның кызлары безгә килеп, әнкәбездән гыйлем өйрәнәләр иде.

Әмма залимнәр, дошманнар, хаиннар, байлар, кулаклар, авыл муллалары безгә тынычлык бирмиләр иде. Падишага каршы булган кешенең хатын һәм балалары дип, исправник һәм становой приставка донос кылалар иде.

Станавой приставлар, жандармнар, залимнәр килеп, безнең өйдә тентү, обысклар кылалар. Атагыздан калган кораллар, мөһер-пичәтләр, яшерен китаплар бар икән дип, өебезне, бөтен бар-юк нәрсәләрне туздырып китәләр иде.

Хәзрәт баба дөньядан үткәч, бабабызның имана җирләрен авыл кулаклары һәм монафикъ муллалары бездән тартып алдылар.

Авылда иген игәргә җир булмагач, күрше авылдагы алпавыттан кыйбат булса һәм ижарә-арендага бер пар дисәтинә җир алып, иген игеп, зирагать-михнәте белән терекчелек кылыр идек. Залимнәр, жандармнар еш-еш килеп тентеп, тикшереп китәрләр иде. Миһербан ана зар-зар елап: «Дәрдмәнд атагызны камаган залимнәр, сез бәгырьләремне дә алып китеп крипескә-зинданга ябуларыннан шикләнәм» — дип моңаеп елар иде.

Бер көн Миһербан ана һәм балалар җыелышып бер мәслихәт кылдык. Карар шул булды ки, авылда фәкать беребез, Гаян абый өйдә, анабыз һәм әбиебез янында торырга. Икебез, Гайнан абый һәм мин Газизҗан, еракта, Төркмәнстанга, Мәрв шәһәренә барып андагы бөрадәрләр янында (бөрадәр — вәисевчеләрнең үзара эндәшүләре. — *К. Ш.*) икамәт кылырга.

Дүртенчебез, ягъни Галәветдин абый Сибириягә Камышов каласына барып, иң зур агабыз Сәлахетдин абыйларда икамәт кылырга.

1901 елда без авылдан, Миһербан анабыздан, абыебыздан, туганнардан, яхшы-

* Киин — соң, соңыннан.

лардан хәер-догалар алып Төркмәнстанга сәфәр кылдык. Көз, сентябрь ахырларында исән-аман Мәрв шәһәренә килеп Ибраһим Шәфизадә Шәрифләргә төштек.

Ибраһим агалар безне зур хөрмәт белән, күп, зур ихлас белән каршы алдылар. Шәфизадә Ибраһим ага кем дисәгез, болгар мөселманнары михнәткәшләрнең вәкилләре, безнең дәрдмәнд атабызның өендә, Казан каласында мәслихәт мәҗлесләре вакытында, залимнәр, жандармнар һөҗүм кылганда, дәрдмәнд атабызның боерыклары белән, яшь вәкилләрдән ике егет, безнең атабызның бакчаларының дивар-коймасыннан күршедәге мәчет бакчасына чыгып, шуннан качып киткәннәр. Шул яшь егетләрдән берсе менә ошбу Ибраһим Шәфизадә икән.

Янә бер яшь егет дәрдмәнд атабызның иң зур өлкән улы Сәлахетдин агабыз икән.

1901 нче елда Мәрвдә, Ибраһим агаларда бер кыш чыктык. 1902 елда март числосы башларында Мәрвдән 60 чакрым Йул Үтән дигән кечкенә бер калага күчеп бардык. Йул Үтәндә Ибраһим аганың үз өйләре һәм зур бакчалары бар иде.

Апрель башларында бакчада эшләр кылган вакытта, Йул Үтән приставы һәм жандармнар солдатлар белән килеп, Гайнан агабызны камап әсир кылып, Йул Үтәннән Мәрвкә төрмәгә алып яптылар. Мин төркмән авылларына барып яшерендем.

Төркмән мәдрәсәсенә кереп, гарәп һәм фарсы телләрендә укыдым. Гайнан абый бер ел ятты. Бер елдан киин суд булды. Янә бер ел зинданда-төрмәдә ятарга хөкем кылдылар. Чөнки Йул Үтән приставы: «Өйләрегезне тикшереп карыйм, сездә яшерен кораллар һәм пичәт вә китаплар бар икән» — дип, өйгә зурлап басып кермәкче булганда, Гайнан абый приставның муенын буа башлаган.

1904 нче ел башларында шәрыкта япуннар русларга зур һәм күп гаскәрләр белән һөҗүм кылып орыш башлагач, падиша вә аның жандармнары-сакчылары куркып, бушап калдылар, чөнки эчкәредә падиша хөкүмәтенә каршылык — революция хәрәкәтләре кузгала башлаган иде.

Ибраһим ага төркмәннәр эчендә мәшһүр иң зур игътибарлы вә бик тә кадерле, хөрмәтле һәм зур гыйлем-белем игәсе иде. Падиша хөкүмәте куркып, бушап, аптырап калганыннан файдаланып, Ибраһим ага һәм төркмәннәрнең зур кабиләләләренең башлыклары таләп кылып, Гайнан агабызны төрмәдән-зиндандан азат кылырга ярдәм иткәннәр иде. Гайнан абый азат булгач, Төркмәнстаннан 1904 нче елда май числосында Казанга кайттык.

Казанда иң зур вә иң мәшһүр мәдрәсәгә укырга кердем. Мәдрәсәнең мөдәррисе Галимҗан дамелла (Галимҗан Баруди. — *К. Ш.*) дигән кеше Бохарада укып галим булган. Галимҗан дамелла дия иде: «Сезнең дәрдмәнд атагыз зур галим һәм тәкъва иде һәм сәяси зур эшләр башлаган. Әмма безнең татар байлары, муллалары, рус падишалары вә губернаторлары таләбе белән атагызга вә аның башлап бара торган юлына чокыр-баз кәүләгәннәр. Мәҗлесләрдә минем алдымда байлар, муллаларга атагызны гайбәт кылырга куймыйм, сез аның тырнагына да була алмыйсыз. Ул хас* мөселман һәм изге кеше, һәм зур гыйлем-белем игәсе һәм зур сәяси вә батыр кеше булган», — дип әйтә иде.

Мәдрәсәдә дамелла миңа шу күренә иде. Әмма байлар вә аларның балалары хәкарәт күзләре белән карыйлар иде. 1904 нче елдан 1907 нче елның ахырынача бик күп фәкыйрьлек белән укыдым.

Минем кем һәм кем баласы икәнемне фәкать дамелла үзе генә белә иде. Киин байлар һәм полиция дә сизә башладылар.

Дошманнар, залимнәр, хаиннарның касид вә зарар кылуларыннан шөбһә кылып 1907 нче ел ноябрь башларында Казаннан Төркмәнстанга һиҗрәт кылдым. Мәрв шәһәренә якын Йул Үтәнгә килеп, бәгъзе яхшыларның дәлаләтләре белән төркмән балаларына хас булган хөкүмәт ышкулында укучы төрекмән балаларын укытучы-мөгаллим булып хезмәт кыла башладым. Ничә еллар укып, укырга-язарга өйрәнмәгән төрекмән балаларын кышта укырга һәм мөселманча язарга өйрәттем.

Кайсы җирдә Муса булса, шунда фиргавен һәм була дигәннәр. Бер-ике ел минем кем икәнемне белмәгән жанадармнар, полициячеләр киин белделәр шикелле. Бераздан залим падишаның залим сакчысы канхур Столыпин министрының приказы белән

* Хас — саф.

укытучылыктан чыгарылып, Себергә выселкага китергә мәҗбүр булдым.

1910 нчы елда Төркмәнстаннан Себергә юнәлеп, мөһим сәбәп белән Чиләбинскидә туктап, шунда азрак торып калдым.

Шул вакытта атабызның зур улы Галәветдин агабыз Чиләбинскидә икамәт кылалар иде. Төркмәнстаннан Себергә выселкага киткәнче, Мәрьям апагыз белән шәргый тормыш кыла башлаганга әле бер ай һәм булмаган иде. «Залимнәр кайда җибәрсәләр дә, сездән аерылып калмыйм», — дип, үз ихтыяры белән Мәрьям апагыз һәм минем белән бергә барган иде. Без Чиләбинскида 1910 елда фәкать февральдән ноябрьгә кадәр генә тордык. Киин авылга, миһербан анабызның хезмәтләренә кайттык.

Залим падишаның залим министрының приказы белән, хәрәмхур татар байлары, монафикъ муллаларының теләкләре белән 1910 елда октябрь урталарында Казанда судебный палата минем үз туганнарым, өч агаларым: Гаян, Гайнан, Галәветдин Бәһаветдин угыллары Вәйсевләрне һәм янә тугыз кеше болгар мөселман михнәткәшләре вәкилләрен — барысы унике кешене, крипескә-төрмәләргә һәм каторгаларга хөкем кылганнар иде. Менә бу мәзлумнарның ата-аналары, хатыннары, балалары Хакка ялварып елыйлар. Миһербан анабыз һәм елап-ялварып безне чакырган иде. Шул сәбәпле ихтыяр вә ихтыярсыз авылга кайтырга мәҗбүр булган идек. Ул елны явымнар булмау сәбәпле, иген-ашлыклар, адәм һәм хайваннарга азыклар кыйбат иде. Авылга кайткач, бер көн дә фәрагать* һәм буш торырга булмады. Әле тирмәннәргә барып, он сатучылардан он алып килеп, әле күрше авылларга барып, хайваннарга печән һәм салам сатучылар бар микән, дип эзләү; әле урманнарга барып, өйләрне җылыту өчен утын эзләп йөрүләр; алпавытлардан кыйбат булса да һәм ижарәгә җир алып, җир һәйдәп, иген һәм урак урып, иген ташып, иген сугу, тирмәнгә барулар һәм башкалар.

Аның өстенә авыл кулаклары, монафикъ, хаин муллалар: «падишага каршы булган кешенең баласы, Себердән, выселкадан качып кайтып бездә авылда яшеренеп тора» — дип күрсәтәләр. 1912 нче елда көз ноябрьдә приставлар, жандармнар килеп, обыск кылып, мине алып киттеләр. Миһербан анам һәм балалар зар кылып елап калдылар.

Әүвәл өязнең воинский начальнигы алдына алып бардылар. Воинский начальниклары аяк тибеп кычкыра, нигә армиягә, солдатка бармыйча качып йөрисең, ди. Мин әйтәм, син кычкырып татарларны куркыткан кеби мине куркыта алмассың, чөнки мин чын болгар һәм чын мөселман Вәйсев улы Вәйсев.

Залим падиша, залим министрлар, залим жандармнар минем атамны, агаларымны һәм болгар михнәткәшләренең вәкилләрене төрмәләргә, себерләргә, каторгаларга камап куйганда, безнең бөтен нәрсәләребезне, һәм җир-суларыбызны талап алганда, безнең балаларны, карт-карчык аналарыбызны ачлыктан, сауктан тилмертеп, төрле налоглар белән җәбер-золымнар кылганда, янә оялмыйча яки безне танымыйча, нигә армиягә падишага хезмәт кылырга бармыйсың дисез, дидем. Начальникның делопроизводителе һәм писерләре мыш-мыш сөйләшеп, «вәт, Вәйсев, вәт герой» — диләр. Начальниклары: «Уберите его саук карцерга», — дип кычкыргач, алып чыгып карцерга яптылар. Карцердан чыгарып, Белоруссиягә — Двинскига җибәрделәр. 1912 нче ел майда Двинскидан лагерьдан качып, Рига шәһәренә бардым. Анда берничә көннәр су буйларында, таш вә агач уемнарында ятып йөргәч, заграницага үтә алырга туры килмәде. Казанга һәм яшерен авылга кайтып, миһербан анабыздан һәм гаилә вә балалардан хәер-догаларны алып, Идел дәрьяның пароходларыннан берсендә фәкыйрь юлчылар белән Астраханьга, аннан Бакуга, Бакудан Батум каласына барып, мәсҗедләрдә һәм Кара диңгез кырыйларында һәм коеп яуган ягъмурларда ачлы-туклы берничә көннәр торгач, анда һәм читкә үтә алмадым. Кире Бакуга, Бакудан Красноводскига, аннан Мәрвкә, Мәрвдән Йул Үтәнгә, Мәрьям апагызның агасы Хафиз абыйларга барып азрак ял иттем. Мәрвдә берничә зур орыш башлангач, бичараларны армиягә орышка ала башлагач, мин Мәрвдән Красноводскига, аннан Астраханьга, аннан яшерен авылга, авылдан миһербан анадан, балалардан хәер фатиха алып, Казанга барып зиярат кылып, аннан Кама дәрьясы белән Перьмгә, аннан Ишемгә, Ишемнән җәяү Абатскига килдем. Инде октябрь, салкын. Карлар, җирләр каткан, ничә көннәр, бәлки ничә айлар, ничә мең чакрым җирләр йөреп, минем киемнәрем, хосусан, аяк киемнәрем тузган иде. Абатскига килеп җиткәндә көн баткан, караңгы төшә башлаган

* Фәрагать — эшсез.

иде. Инде кая барыйм дип уйлап, арган, сауктан туңган аякларым белән акрын-акрын атлап барганда, Абатскида бер кеше күчәдә бу якка килгәне күренде дә, бәлки, яхшы кешедер дип, эчемдә Хак Тәгаләгә ялварып, азрак туктап тордым. Әлеге кеше килеп сәлам бирде, күреште. Сәлам биреп, сауктан туңган кулларым белән әлеге кешенең ышык кулларын кысып азрак эчемә бераз җылы кергән кеби булды. Ул кеше кем икән дисәгез, Нургали Тимергали улы әл-Болгари иде (Хак Тәгаләнең рәхмәтендә булсалар икән!).

Менә Хак Тәгаләнең ярдәме, атагыз Нургали агабызның Нигъмәт сайәсендә җылы өй һәм җылы киемнәр һәм җылы майлы ашлар булды. Аерым бер фатир алып, җылытып, менә шунда сез яшь балаларны бер кыш укыттым. Укыганнарыгыз һәм белгәннәрегез, әлбәттә, исегездәдер. Атагыз Нургали ага күп яхшы вә зур һиммәтле иде. Хак Тәгаләнең рәхмәте вә ярдәме белән, бәлки, бер көн исә дә аман, азат булып кайтып килер, шаять шатлык көннәре һәм булыр.

Нургали Болгари яхшы тугры кеше дип, Абатскиның руслары һәм өч-дүрт өй татарлар вә мишәрләр һәм хөрмәт кылалар иде. Бәлки шуның өчендер, хәзер сугышорыш вакытында менә бу яшь кеше бер яудан качып, яшеренеп йөрми микән дип, сораучы, безне тикшерүче булмады. Әмма орыш көннән-көн зурая. Бичара халыкларны йөзләп, меңләп орышка һәйдиләр. Залим немецлар, фашистлар мәзлумнарны кырып торалар. Җылыда, буранда, салкында, үзеңә һәм якын дусларыңа ышык һәм җылы урын тап. Яки исең һәм хәлең барында илең тап, дигәннәр.

Менә без, Нургали агаларыбыз белән мәслихәт кылып, өйдәге балаларны, бөтен гаиләне, җәмәгатьләрне калдырып, үзебез Кытай җиренә барып, орышлар туктаганчы читтә торырга карар кылдык.

Нургали һәм Нурмөхәммәд Болгарилар поезд белән Ишемнән Омскига барырга булдылар. Мин Абатскийдан Ишемтамакка барып, анда (выселкадан-төрмәдән азат булгач) торучы Гайнан агабыз белән күрешеп, хәбәрләшеп, Иртыш дәрьядан пароход белән Симигә, аннан Зайсанга бардык. Нургали һәм Нурмөхәммәд Болгарилар белән өчебез Зайсанга бардык. Зайсаннан ат һәм иярләр алып, өчебез өч атка менеп юл күрсәтүче казакъ белән чигәрәдән исән-аман үтеп, Кытай җиренә аяк бастык, юл күрсәтүче Зайсан казагы белән хәерләшкәч, без кырларда, тау буйларында адашып, бер-ике көн ач йөргәч, киин казаклар Әхмәдгали дигән сәүдәгәр казакъны күрсәттеләр.

Әхмәдгалиләр безне кадер-хөрмәт белән каршы алдылар. Дәррәү чәй кайнатып бавырсак белән, каймак белән чәй эчерделәр. Кич белән симез туклы* суеп, бер казан ит пешерделәр. Бер кич Әхмәдгалиләрдә кундык, иртәсе Нургали ага Болгари, Нурмөхәммәд Болгарилар белән хәерләшеп, Әхмәдгалиләргә рәхмәт әйтеп, мин ялгыз казакъ далаларыннан үтеп, күп кыенлыклар, мәшәкатьләр белән Уйгурстанга, Шәркый Төркестанга бардым.

Нургали ага Болгари, Нургали Мөхәммәд Болгарилар Әхмәдгалиләрдә кунак булып калдылар, шуннан киин без бер-беребезне күрмәдек.

Шәркый Төркестан — Уйгурстанда 1918 нче ел июль башларына кадәр сәяхәт кылдым. Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары, зур үзгәрешләрне Шәркый Төркестан — Уйгурстанда ишетеп белеп, Хак Тәгаләгә тәвәккәл кыйлып, ватаныбызга кайтырга чыктым. Исән-аман Зайсанга килеп, аннан Иртыш дәрьяның башларында пароходка утырып Омскига килдем.

Омскида поезд көтеп бер көн тордым. Монда күчәдә гәзит сатучылар кычкырып яңа хәбәрләр: падиша Николай Второйны бөтен җәмәгатьләре белән Свердловскида большевиклар атканнар һәм кое-кадакага күмгәннәр дигән гәзитне укып, залимнең кылган җәбер-золымнары, безнең һәм аналарыбызның һәм балаларның күз яшьләре залим канхур падишаның вә җәмәгатьләренең башларына бәла булып төшкән, дидем. 1918 ел башларында Омск һәм бөтен Себер һәм Уфа вә Самар чехлар вә ак гвардия, байлар, чиновниклар, поплар, муллалар ихтыярында иде.

Хак Тәгаләнең ярдәмендә шөкер, исән-аман һәм азатлык белән өйгә, авылга, миһербан ананың хозур шәрифләренә кайттым. Миһербан ана шат, хөррәм булып Хакка шөкерләр кылды. Анабызның янында Гайнан агабызның хатыны һәм балалары бар иде.

* Туклы — сарык.

Авылда көн күрүләр кыен булгач, Мәрьям апагыз өч яшлек кызыбыз Мәдинә белән, зур үзгәрешләрдән элгәре Төркмәнстанга, Мәрвгә, агалары янына киткән икән. Гайан агабыз, инкыйлабтан элгәре зиндан-төрмәдән азат булып, Белоруссиягә выселкага җибәрелгән икән.

Гайнан агабыз исә Февраль революциясендә хибестән азат булып, Казанга кайткан икән. Октябрь инкыйлабының башларыда 1918 ел 28 нче февральдә Казанда татар байлары, монафикъ муллаларның ялчылары, залим хаиннар, ак гвардиячеләр, Колчак офицерлары мәҗлес вакытында тәрәзәдән наган белән атып шәһид кылганнар.

Менә ошбу белән тарихи мәгълүмат вә сәяхәтнамәләрнең беренче кыйсеме тәмам. Күзләребез нормальный яхшы күрми. Йөрәк дәртебез зур. Кулларыбыз һәм калтырап китә. Шул сәбәпле язган язуларыбыз хәрефләре, ноктала тигез булмый. Шаять вакытларыгыз булганда дикъкать вә саф күңел белән «һуа хак»*, дип табып, кабат укырсыз. Бәлки яхшы аңларсыз һәм шаять юаныч булыр.

Исән-аман булсак, икенче кыйсемен һәм акрынлап язып тәмам кылырга насыйп булса, бер заманнан киин сезгә җибәрербез. Тарихи ядкәр булыр.

Азатлык, хокук, хөррият, җир-су таләп кылып көрәшүче михнәткәш фәкыйрь болгарларның вәкилләре, дәрдмәнд атабыз Бәһаветдин Вәисевнең өйләренә фәүкыльгадә** мәҗлескә килеп, залим хаин падиша вә аның сакчылары жандармнар, байлар, муллалар вә бөтен карагруһларның һөҗүмнәренә очрап төрмә вә себерләргә һәйдәләргә мәҗбүр булучыларның исемнәре менә ошбулар:

Беренче — бабабыз (анабызны бала кылып, яшьтән багып, тәрбия кылып үстергән һәм укыткан атасы) Габделлатыйф Халиди, Сембер вилайәте Бидәнге карьясе имамы, әһле гыйлем, Казанлык һәм бөтен Идел-Урал буйларындагы мөселманнар эчендә зур хөрмәтле булу сәбәпле фәкать бер елга төрмәгә Йәдринә каласына җибәрелгән.

Икенче — Гали баба — зирагатьче, Зөя өязе Карашәм авылының могтәбәр*** карты.

Өченче — Әхмәҗән Хаҗи баба, фәкыйрь һөнәрмәнд, укытучы, Казан арты Арча ягы. Саук Себергә һәйдәлгән.

Дүртенче — Йосыф баба, Арча ягы Бәрәзә авылының зирагатьчесе һәм әһле гыйлем. Себергә һәйдәлгән.

Бишенче — Шакиржан баба, Казан арты фәкыйрь зирагатьчесе, Себергә һәйдәлгән.

Алтынчы — Мифтах баба, фәкыйрь зирагатьче, Себергә һәйдәлгән.

Җиденче — Сабит баба, фәкыйрь зирагатьче, Себергә һәйдәлгән.

Сигезенче — Фәиз баба, фәкыйрь зирагатьче, Себергә һәйдәлгән.

Тугызынчы — Нуретдин баба, фәкыйрь зирагатьче һәм һөнәрмәнд, Себергә һәйдәлгән.

Унынчы — Гыйльман баба, фәкыйрь зирагатьче, Себергә һәйдәлгән.

Унберенче — Мохтар баба, Зөя өязе Мулла Иле авылының зирагатьчесе, һәм могтәбәр карты.

Уникенче — Гыйззәтулла баба Хәмидулла улы, Казан арты, Арча ягы, һөнәрмәнд.

Фәүкыльгадә вәкилләр җыелганда, хазир булучылардан залимнәрнең һөҗүм вә әсарәт кыйлуларыдан хәляс булып, исән-аман качып нәҗат булучылардан:

Берсе — дәрдмәнд атабыз Бәһаветдиннең иң зур улы, агабыз Сәлахетдин.

Икенчесе — Ибраһим Шафизадә. Болар өйнең бакча-багъ диварыннан ашып, тыныч урам-күчә тарафына чыгып, исән-имин качып, хәляс булганнар.

Агамыз Сәлахетдин исән-аман Сибириягә барып, Камышлов каласында ахыр гомерләренә (1892) кадәр, фрукты һәм яшелчә кәсебе белән яшәгән.

Ибраһим Шафизадә исә, Төркмәнстанга барып, Мәрв шәһәрендә хөкүмәт идарәләрендә кятиб һәм тәржеманлык эшләрендә 1905 нче елга кадәр яшәгән.

С. Р. Газизҗан (Дәрдмәнд ибне Дәрдмәнд) задә әл-Болгари.

Камил Шәкүревнең шәхси архивыннан.

РЕЗЮМЕ

Статья К. Шакурова о ваисовском движении предваряет публикацию документа — воспоминания последнего лидера ваисовского движения Газизяна Ваисова. В них автор рассказывает о своей тяжелой жизни, полной испытаний и преследований.

* Һуа хак — бу дөрес.

** Фәүкыльгадә — чиктән тыш, мөһим.

*** Могтәбәр — игътибарлы, хөрмәтле.